ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

30.07.2021 | 21

с. Кильдеево

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге территориясендә
профилактик эш төркеме төзү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарны үтәү йөзеннән, янгыннар һәм аларда кешеләр үлеме шартларын тотрыкландыру, торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре турында хокукый агарту һәм халыкка хокукый мәгълүмат бирү формасында профилактик чаралар үткәрү, гражданнар арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау максатларында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге чикләрендә халыкка торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре турында хокукый мәгълүмат бирү, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә янгынга каршы пропаганда буенча профилактика эш төркеме составын раслау (1 кушымта).
2. Профилактик эшче төркем әгъзаларына торак пунктларның торак секторының җаваплылыгы зонасын беркетергә һәм аларның көче белән хокукый агарту һәм халыкка торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре турында хокукый мәгълүмат бирү, янгынга каршы пропаганда формаларында профилактик чаралар үткәрергә.
3. Профилактик төркемгә:
   - Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Югары Ослан янгын-коткару гарнизоны бүлекчәләре хезмәткәрләре

(хезмәткәрләре), Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» МБ хезмәткәрләре, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссиясе, күпбалалы гаиләләрдә, социаль яклау органнарының попечительләр исәбендә торучы гаиләләрдә профилактик чаралар эшен оештыру өчен алар белән хезмәттәшлек итәргә;

- ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, социаль яктан имин булмаган халык катламнары һәм амораль яшәү рәвеше алып баручы затлар белән эш оештырырга;

- 2021 нче елның октябрь аена кадәр Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең торак секторына тикшерү үткәрергә;

- атна саен җомга көннәрендә Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге торак пунктларының торак секторын тикшерү нәтиҗәләрен тапшырырга Югары Ослан муниципаль районы буенча ГТХМ һәм Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе хезмәткәрләре.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин

1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге чикләрендә халыкка торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре турында хокукый мәгълүмат бирү, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә янгынга каршы пропаганда буенча профилактика эш төркеме
СОСТАВЫ

Эшче төркем рәисе:

| | |
|---|---|
| Бурдин Виктор Михайлович | Килди авыл җирлеге башлыгы |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Илалова Лилия Инсаф кызы | Россия Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча УНД и ПР Баш идарәсе Югары Ослан муниципаль районы буенча ОНД һәм ПР инспекторы |
| Макаренко Артем Юрьевич | Россия ГХМның Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең 112 ПСЧ ФПС ГПС бүлеге командиры (Харино авылы) |
| Прохоров Сергей Сергеевич | ОП ППС РТ Рус Макылы авылы вәкиле (Кильдеево авылы, Уланово авылы, Федяево авылы) |
| Горбачева Юлия Анатольевна | Югары Ослан муниципаль районы социаль яклау органнарының Попечительлек исәбендә торучы күп балалы гаиләләрдә, гаиләләрдә профилактик чаралар оештыру өчен балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе вәкиле. |

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин